ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КРЫНДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КЫРЫНДЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.11.2025 Кырынды авылы № 13

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кырынды авыл җирлеге Башкарма комитетының «Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы 2022 елның 24 мартында кабул ителгән № 6 карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив-хокукый актларны Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатларында, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендә кабул ителгән 210-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 31 июлендә кабул ителгән 304-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кырынды авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кырынды авыл җирлеге Башкарма комитетының 2022 елның 24 мартында кабул ителгән «Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы № 6 карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1) 2.5 бүлектәге 2.5.1 пунктының 4нче өстәмә пунктында "мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси мәгълүматларын эшкәртү кирәк” сүзләрен “мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси мәгълүматлары бирелергә һәм эшкәртелергә тиеш” сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кырынды авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://www.agryz.tatarstan.ru) һәм “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru

2. Бу карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы Р.Р.Мәүликаев